МАХСУС ОПЕРАЦИЯ
Дөнья күчәре Украинадагы вакыйгалар тирәсендә әйләнә

> 2

РАЙОН ҮСЕШТӘ
Фәрит Мөхәммәтшин Менделеевск районына сәфәр кылды

> 2

АКЧА ҖИТСЕН
Россиядә азык-төлек бәяләрен йөгәнләмәкчеләр

> 2

ТЕЛ САКЧЫСЫ
Татарстан журналистлары танылган галим Илдар Низамов белән хушлашты

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 29 (28802) | Сишәмбе | 1 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Без шәхесләрнең ил, халык язмышында нинди урын тотулары турында беләбез. Шул ук вакытта тарихның билгеле бер чоры үзе шәхесләрне тудыра. Кыйблалар буталган, ил диңгездәге ялгыз көймә кебек чайкалган туксанынчы елларда безгә, бәлки, нәкъ менә Минтимер Шәймиев кирәк булгандыр, аны безгә язмыш үзе биргәндер. Әлбәттә, зур эшләр башкарырга алынган шәхесләргә фикердәшләр, ул башлаганны лаеклы дәвам итеп, яңа дәрәҗәгә күтәрүчеләр дә кирәк. Һәм шул вакытта сәяси сәхнәгә Рөстәм Миңнехановның чыгуын да «язмыш кушуы» дип кабул итү дөрес булыр иде.

tatarstan.ru

ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЕШЕ

Заманында карьера баскычлары буйлап шактый тиз атлап югарыга менгән Рөстәм Нургали улына шикләнебрәк караучылар да табылган иде. Янәсе, ул әле яшь, тәҗрибәсе дә җитеп бетми, зур сәясәткә дә кереп кенә барышы. Әмма Минтимер ага нигез салган «яңа Татарстан»ның тагын да ныгуы, үсешкә юл тотуы бөтен шикләрне юкка чыгарды.

Минем Рөстәм Миңнеханов белән институтта бергә укыган бер танышым бар. Рус кешесе ул үзе, әмма татарчасы да әйбәт. Рөстәм Нургали улы Президент булып билгеләнгәч, әлеге танышым бер дә гаҗәпләнмәде. «Студент чакта без тусовкаларга да йөрдек, кызлар да озаткаладык, күңел ачарга да бик ярата идек, әмма Рөстәм безгә бер дә иярми иде, гел укыды да укыды», – дигән иде ул. Димәк, зур эшләргә алдан әзерләнгән булачак Президент. Инде менә шул зур эшләрне берәм-берәм күңелдән үткәреп утырыш.

Президент кәнәфие кызыга торган урын түгел. Ул – Татарстан, алай гына да түгел, ил, алай гына да түгел, бөтен дөнья буйлап сибелгән татар халкы язмышы өчен дә җавап тота торган урын. Ниндидер бер җыелышта Рөстәм Нургали улы үзе дә: «Халык без биләгән урынга түгел, кылган гамәлләребезгә билге куячак», – дигәнрәк сүзләр әйткән иде. Шушы сүзләрне үзе өчен алтын кагыйдә санап, төптән җигелеп тартмаса, Татарстанның даны илгә-җиргә таралмас иде.

«Алгы тәгәрмәчләр кая барса, арттагылары шунда таба бара», – диләр. Дустым, күренекле шагыйрь Зиннур Мансуров бер көнне миңа: «Ни генә әйтсәң дә, без Президенттан уңдык», – дигән иде. Соңгы сайлауда аның ышанычлысы булып төрле очрашуларга йөрде ул. Сүзгә үтә дә саран Зиннурның авызыннан шундый сүзләр ишеткәч, бераз аптырап та калган идем. Әмма ул Президентның халыкка, халыкның Президентка мөнәсәбәте турында шактый ук дулкынланып сөйләде дә: «Ни дисәң дә, Миңнеханов үз кеше инде», – дип куйды.

«Үз кеше» димәктән, безнең Президентка ил җитәкчелеге дә зур ышаныч белдерә. Президент командасыннан инде ничә кешебез федераль хакимияттә җаваплы урыннарда эшли. Ил өчен әһәмиятле күп кенә проектлар, ачышлар еш кына иң әүвәл Татарстанда сынала. Димәк, кулыбыздан эш килә. Инде «Татарстан тәҗрибәсе» дигән сүзләр телгә керде. Безнең бөтен уңышлар, иң беренче чиратта, Президентның абруе, тырышлыгы белән бәйле. Ул шулай булырга тиеш тә. Ил җитәкчелегенең Татарстан сүзенә, аерым алганда, Президентыбыз фикеренә колак салуы, аңа ышануы – куанычлы хәл.

Бүген без «инновация» дигән сүзне дә бик еш куллана башладык. Инновация – югары нәтиҗәләргә ирешерлек яңалык кертү, базарда ихтыяҗ, көндәшлек тудырырлык продукция җитештерү. Бу продукция дигәннәре тормышыбызның һәр өлкәсенә кагыла: мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль тармакларда да иртәге көнне уйлап эшләргә тиешбез, һәм шуңа таба барабыз да.

Иннополис шәһәренең нәкъ менә бездә калкып чыгуын әйтсәк, иртәге көн, киләчәк белән яшибез дигән сүз. Бу алгарышта да «беренче скрипка»ны иң әүвәл Президент уйнарга тиеш иде, һәм бу шулай да. Рөстәм Нургали улының инде менә 12 ел буе Россиянең инновацияле төбәкләр ассоциациясе советын җитәкләве дә тикмәгә генә түгел.

Бүген Рөстәм Миңнехановның бөтен уңышларын санап тормыйбыз, бу кирәк тә түгел. Чөнки аның бөтен эшчәнлеге халык күз алдында. Социаль челтәрләрдә активлыгы буенча ил төбәкләре җитәкчеләре арасында алдагы урында ул, бу аның халыкка иң якын җитәкчеләрнең берсе икәнен тагын бер кат раслый.

Җитәкчеләрнең була җитәкчелек итәргә яратканнары, була эшләргә яратканнары. Президент тарафына төче сүзләр әйтәсе килми, артык мактаганны үзе дә яратмый кебек ул. Игътибар иткәнем бар: җыелышларда мактау, рәхмәт сүзләре артык мул ява башласа, утырган урынында тынычсызлана башлый. Бер кызык сөйләделәр әле. Зур шәһәрләрнең берсендә, әле Премьер-министр чагында, бер җыелышта катнаша Рөстәм Нургали улы. Шәһәр башлыгы зур җитәкче алдында, әлбәттә инде, яхшырак күренергә тырышып, уңышлар турында рухлана-рухлана сөйли, хөкүмәт җитәкчесенә әледән-әле рәхмәт сүзләре яудыра. Премьер-министр түзми: «Иркәм, син матур сүзләр сөйләмә, эш турында сөйлә!» – ди. Аның бу сүзләре бер гыйбрәткә әйләнеп, башкалар теленә дә кереп киткән иде әле.

Минем дә артык матур сүзләр язасым килми, бары тик Рөстәм Нургали улының эшләргә яраткан җитәкче булып туганын гына әйтмәкче булам.

Заманалар үзгәрә, тора-бара төбәк, республика җитәкчеләрен өстән билгели башларга да мөмкиннәр. Ярый әле, безнең Президентыбыз – үз кеше. Аңа исәнлек-саулык телик!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Теманың дәвамы 5 нче биттә >

Концертларга кагылмый

28 февральдән халык катнашындагы массакүләм чаралар үткәрү тыела. Бу хакта карарны Татарстан Хөкүмәте кабул итте. Әлеге чикләү республикада санитар-эпидемиологик хәл уңай якка үзгәргәнче гамәлдә булачак.

Шулай да, Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстанда кайбер чаралар үткәрү рөхсәт ителә. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе матбугат хезмәтендә бу үзгәрешнең нинди чараларга кагылмавын аңлаттылар.

Хөкүмәт карары нигезендә Татарстанда күңел ачу, ял итү, спорт, физкультура, күргәзмә, реклама чараларын үткәрү тыелмый. Моның шартлары бар. Әйтик, ачык һавада оештыра торган чараларда кеше саны 200дән артырга тиеш түгел. Бина эчендәге чаралар өчен кеше саны 100дән артмаска тиеш (1 кешегә 4 кв. м мәйдан туры килгән очракта).

Татарстанда театр, кинотеатр, цирк, концерт, тамаша залларына (70 процентка тутыру шарты белән) эшләргә, рәсми физкультура һәм спорт, мәдәни чаралар (халык саны 500 кешедән дә артмаган очракта) үткәрергә рөхсәт ителә. Барлык хезмәткәрләр дә коронавируска каршы прививка кадаткан һәм чара үткәрергә 30 көн кала Министрлар Кабинетының санитар-эпидемиологик комиссиясе белән килештерелгән очракта бу чараларны 70 процентка тулган залда уздырырга ярый.

67се җавап тотачак

Узган атнада рөхсәт ителмәгән акцияләрдә катнашучылар, тоткарланып, җаваплылыкка тартылган. Әйтик, 24 февральдә Казан шәһәренең Бауман урамында тиешле органнар белән килештерелмәгән чара уздырылган. Нәтиҗәдә 21 кеше тоткарланган (1се – балигъ булмаган үсмер). Алар буенча суд карары чыгарылган да инде. Күбесе 5әр мең сумга штрафка тартылган, ә инде законны кабат бозучылар 10 тәүлеккә кулга алынган.

27 февральдә рөхсәт ителмәгән шундый ук ике акция уздырылган. Барлыгы 46 кеше тоткарланган. Һәркайсына карата Административ хокук бозулар турындагы кодексның 20.2 статьясы буенча беркетмәләр төзелгән.

Хокук саклау органнары кисәтә: рөхсәт ителмәгән акцияләрдә катнашкан өчен 20 меңнән 30 мең сумга кадәр күләмдә штраф яки 50 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләргә җәлеп итү күздә тотылган. Ә инде законны кабат бозган өчен 150 меңнән 300 мең сумга кадәр штраф яисә 30 тәүлеккә кадәр кулга алу каралган.

Ярдәм артачак

Быел Татарстанда эшмәкәрләргә ярдәм итү өчен республика бюджетыннан 4,5 миллиард сумнан артыграк акча бүлеп биреләчәк. Бу хакта Икътисад министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итә. Республикада бизнес өчен башта 1,2 миллиард сум каралган булган. Әмма Икътисад министрлыгы карамагындагы фондлар – Татарстанда Эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм Гарантия фондларының капиталы арту нәтиҗәсендә, гомуми сумма 4,5 миллиард сумнан артып киткән.

Эшмәкәрләргә ярдәм йөзеннән ташламалы займнар һәм микрозаймнар биреләчәк, шулай ук процентларны түләү чыгымнары субсидияләнәчәк.

Атна ахырында суыта

Язның беренче атнасында Татарстанда җылы һава күтәелә. Синоптиклар әйтүенчә, ял көннәренә кадәр һава температурасы көндез 1 градуска кадәр җылыначак. Ә инде шимбәдә 5 градуска кадәр суыта. Республикада 2 һәм 3 мартта көндез температура –5…+1 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә һава температурасы –6…–12 градус тәшкил итәчәк, явым-төшем юк. Юлларда – бозлавык. Җомга – 4 мартта урыны белән аз гына кар явачак. Көндез –4…+1 градус, төнлә –4…–9 градус салкын булачак. Шимбә – 5 мартта һава торышы начарлана. Юеш кар, урыны белән буран, көчле җил күтәелә. Көндез 0…–5 градус, төнлә –3…–8 градус салкын.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Актуаль тема

«Алло» диюдән башлана

Оят та, иман да юк! Һәр нәрсәдән үзенә файда табу ягын караган мошенниклар бу көннәрдәге вазгыятьтән дә отып калырга тырыша. Хәзер алар санкциягә эләккән банк клиентларына акчаларын саклап калырга «ярдәм итә» башлаган.

Билгеле булганча, бу көннәрдә Россиядәге банкларның күбесенә карата чикләүләр кертелде. Европа берлеге аларны SWIFT халыкара түләү системасыннан чыгарырга җыена. Кырыгалдарлар, әнә шушы яңалыкны сәбәп итеп, санкциягә эләккән банк клиентларына шалтырата башлаган. Мошенниклар иң элек үз корбанын, бер мизгел эчендә акчаңны югалта аласың, дип куркытып куя. Аннары аңа булган акчасын тиз арада ышанычлы счетка күчерергә тәкъдим итә, ди белгечләр. «Телефоннан шалтыраткан шикле зат киңәше буенча беркая да акча күчерергә ярамый. Ышанычлы счет дигән төшенчә юк. Алар бу очракта үзләренең шәхси исәп-хисап счетын күздә тота. Шуңа күрә әгәр сезгә шундый гозер белән шалтыратсалар, тиз арада телефонны куярга кирәк. Акчагызга, дөрестән дә, куркыныч яныймы-юкмы икәнлеген исә банкка шалтыратып белешә аласыз. Сезгә кирәкле номер банкның рәсми сайтында яки банк картагызның арткы ягында күрсәтелгән», – диелә Үзәк банк хәбәрендә.

Ни кызганыч, мошенниклар тарафыннан алдануыбыз соңгы арада гадәти күренешкә әверелеп бара. Белә торып алданган очраклар да байтак. Саннар да шул хакта сөйли. Рәсми мәгълүматлардан аңлашылганча, Россиядә ел саен 400 меңләп кеше телефон аша эш итүче кырыгалдар корбаны була. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада көненә уртача 30 кеше телефон аша алдана. Әле соңгы бер атна эчендә генә дә кырыгалдарлар республика халкын 41,5 миллион сумга төп башына утырткан.

Психология фәннәре кандидаты Лилия Һадиева моны җәмгыятьтә елдан-ел көчәя барган киеренкелек, курку, билгесезлек «җимеше» дип саный.

– Халык ике елдан артык пандемия шартларында җитди чир иярүдән, үлем-китемнән куркып яшәде. Бу көннәрдә җәмгыятьтә хөкем сөргән вазгыять бу хисләрне бермә-бер арттырды. Курку аңны томалый. Мондый хәлдә адәм баласы акылдан бигрәк, эмоцияләр белән эш итә. Даими рәвештә стресс, паника шартларында яшәгән кеше, ирексездән, читтән ярдәм көтә башлый. Шуңа күрә ярдәм тәкъдим итүче булса, аңа шундук ышана, ул әйткәннәрне киңәш итеп кабул итеп, төгәл үти башлый. Мошенникларның нәкъ менә шундый болганышлар вакытында аеруча активлашуы әнә шуның белән аңлатыла да инде, – ди белгеч. – Берничә кагыйдәне истә тотарга киңәш итәм. Мошенник – бик оста психолог. Ул кешедә ни рәвешле, нинди сүзләр белән ышаныч уятырга кирәклеген бик яхшы белә. Шуңа күрә еш кына аның алдакчы икәнен җиңел генә ачыклап та булмый. Шулай да аны «сата» торган берничә сыйфат бар. Әйтик, кырыгалдар еш кына кыска-кыска җөмләләр белән, бик тиз сөйли. Моны ул махсус кешенең аны-моны уйларга, анализларга вакыты булмасын өчен эшли. Аның күп кенә сүзләре боерык сыман яңгырый. Әгәр кеше озак уйлап торса, ул әйткәннәрне эшләүдән баш тартса, мошенник, ачудан тавыш күтәрергә, дорфа сөйләшергә дә мөмкин. Чын банк хезмәткәре үзен беркайчан да болай тотмаячак.

Шуңа күрә телефонга ят номер шалтыратса, аңа бөтенләй җавап бирмәвең хәерле. Сөйләшергә туры килгән очракта исә үзеңне тыныч тотарга, аларга берни аңлатмаска, акланмаска, дәлилләмәскә, бернинди вәгъдәләр бирмәскә кирәк, ди белгечләр. Мошенникның соравына сорау белән җавап бирергә, сөйләшкәндә «әйе», «юк» сүзләрен дә бөтенләй кулланмаска кирәк.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Игорь КОНАШЕНКОВ, Россия Оборона министрлыгының рәсми вәкиле:

Россия Кораллы көчләреннән махсус хәрби операциядә офицерлар белән рядовой һәм сержант вазыйфасында контракт буенча хезмәт итүче хәрбиләр генә катнаша.

РОССИЯДӘ – ЭШСЕЗЛЕК

Татарстан узган ел эшсезлек күрсәткече иң түбән булган төбәкләр исемлегенә кергән. РИА «Новости» уздырган тикшеренү нәтиҗәләре әнә шундый.

	Төбәк	2021 елда эшсезлек күрсәткече	2020 ел белән чагыштырганда	Эшне ничә ай эзлисе
1	Санкт-Петербург	1,5	- 2,1	3,9
2	ХМАО	1,8	- 0,8	5,4
3	Мәскәү	2,1	- 1,1	4,2
4	**Татарстан**	**2,3**	**- 1,3**	**4,3**
5...	Хабаровск крае	2,4	- 1,1	4,0
...81	Тыва	10,5	- 7,8	7,5
82	Чечня	10,9	- 10,1	7,7
83	Т.Осетия – Алания	12,1	- 2,7	11,7
84	Дагыстан	13,6	- 2,3	9,9
85	Ингушетия	30,0	- 1,6	6,9

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АТОМ БОМБАСЫ ШАРТЛАМАСЫН

Үткән атнада башланып киткән махсус операция бүген бөтендөнья матбугат чараларының игътибар үзәгендә. Мәгълүмат кыры фейк һәм фейк булмаган хәбәрләр белән тулып ташый, берсен икенчесеннән аерып алу да кыен. Әмма бер нәрсә ачык аңлаешлы: аны дөнья җәмәгатьчелеге кабул итә алмады, планетакүләм зур протест акцияләре оешты, Көнбатыш илләре бердәм рәвештә Россиягә каршы икътисади сугыш игълан иттеләр. Санкцияләрнең өченче пакеты тормышка ашырыла башлады инде. Искә төшерәбез: барысы дүрт «тыю» пакеты планлаштырылган иде. Өченчесе – икенчесеннән, икенчесе беренчесеннән катырак. Әлегә дүртенче пакет запаста саклана.

Махсус хәрби операция планлаштырылганча ук бармый. Мәскәү икенче көнне үк инде сөйләшүләр өстәле янына утыру тәкъдиме белән чыкты, әмма Киев «сөйләшү без куйган шартларда гына башлана ала» дип үҗәтләнеп кире какты. Шулай да якшәмбе көнне алшартларсыз гына сөйләшүләрне башлап җибәрү турында килешүгә ирешелде. Дүшәмбе иртәсе бу юллар язылганда, әле диалог башланмаган иде, әмма аннан зур нәтиҗә көтәргә ярамый.

Россия конфликтка уңайсыз фонда керде. Дөнья җәмәгатьчелеген һәм сәясәт элиталарын «Киевта фашистлар утыра» дигән формулага ышандырып булмады. Икенче тәүлектә үк «бандерачы»ларга финанс һәм хәрби ярдәм күрсәтелә башлады. 28 февраль көнне видеоконференция форматында АКШ, ЕС һәм алты Европа дәүләте, НАТО, Канада, Япония җитәкчелегенең сөйләшүе көтелә. АКШның БМОдагы вәкаләтле вәкиле соңгы унъеллыкларда беренче тапкыр БМОның Генассамблеясы чакырылуын искәртте.

Гомуми фон начараюын дәвам иткән бер мизгелдә, Владимир Путин оборона министрына һәм Генштаб җитәкчесенә «тоткарлау көчләре»н «аерым хәрби кизүлек режимы»на күчерү турында әмер бирде. Бу хәбәрне ишеткән һәркемнең йөрәге дерт итте. Мәскәү асылда соңгы уен картасын өстәлгә чыгарып салды һәм моны Көнбатышта җитди кабул иттеләр. Бу карарны АКШта Берләштерелгән штаблар җитәкчелеге комитеты һәм АКШның Европадагы көчләре җитәкчелеге катнашындагы киңәшмәдә тикшерделәр. Вашингтон фикеренчә, әмер Россия гаскәрләре дүрт тәүлек эчендә сугыш кырында көтелмәгән уңышсызлыкка очраганда бирелде. Пентагон вәкиле әлегә бу хакта мәгълүмат җыюларын, әмма Путин карарының хәвеф уятуын әйтте. Хәл бик киеренке, әлбәттә, әмма атом-төш шартлавы булмас, аек акыл өстенлек итәр. Тик Киевта очрашуның уңышлы буласына бик ышанып бетмиләр әле никтер. НАТО блогы Украинага хәрби юк итүче очкычлар бирәчәген рәсми игълан итте. Димәк, махсус операция дәвам итәчәк. Шулай да «Ватаным Татарстан» хәбәрчесенең фаразы яхшы бу мәсьәләдә. Масштаблы зур шартлау булмаячак, тактик атом-төш бомбасы шарт итү ихтималы бик кечкенә генә бар-барын. Без Толстойның мәшһүр романы исемен «Махсус операция һәм тынычлык» дип үзгәртергә дә риза, бомба гына шартламасын.

Россиядә

ДОЛЛАРСЫЗ НИШЛӘРБЕЗ?

Махсус операциянең бәясен без бүген үз кесәләребез белән сизәбез. Якшәмбедән дүшәмбегә каршы төндә газета хәбәрчесенең телефонына доллар курсы турында хәбәрләр явып торды. Тинькофф Банк кичтән долларны 153 сумнан сата башлаган иде, таң атканчы бәя 192 сумга күтәрелде. Иртән биржа ачылганда, Американың яшел кәгазе биржа мәйданында 105 сум белән бәяләнә башлады. Без валютаны биржадан алмыйбыз бит инде, банклардан алабыз. Саклык банкында доллар 113 сум тирәсе, диделәр. Газета хәбәрчесенең 2014 елгы паника алдыннан кулында берничә мең доллар валютасы бар иде. Бу юлы кесәләр шыр. Вәләкин бер дә борчылмыйбыз әле.

Валюта түнтәрелешенең берничә җитди сәбәбе бар. Бердән, көнбатышлылар Россия Үзәк банкының валюта резервларының яртысын «туңдыру» турында карар кабул иттеләр. Димәк, «кара көн»гә дип җыелган 300 миллиард доллардан артык акча – «суыткыч»та, аны файдаланып булмый. Икенчедән, Россия банкларының байтагы халыкара түләүләр системасы SWIFTтан өзелергә мөмкин. Бу сәүдәне кыенлаштыра. Әле ярый барлык банклар түгел. Безнең бик күп егетләр өйдә утырган килеш Көнбатыш компанияләренә эшлиләр бит, интеллектларын валютага алыштыралар. Валюта исә нәкъ менә шул SWIFT системасы аша илгә кайта, базарны тотрыкландыруга хезмәт итә. Бу нефть сатканга караганда отышлырак. Интеллект саткан саен арта бит, кимеми.

Иң җитди сәбәп: эре банкларга доллар белән эш итү тыелды. Бу аларның АКШтагы корреспондент хисапларын ябуны аңлата. Доллар белән исәп-хисап ясарга теләгән һәр банкның шундый корреспондент хисабы булырга тиеш. 600 миллиард долларлык активлары булган Саклык банкы, мәсәлән, хәзер чит илдән валюта кайтара алмый. ВТБ, «Открытие» дигән банклар да шулай ук. Бу банклар моңарчы сату өчен долларларны самолетлар белән тонналап ташый иделәр. Санкцияләр кертелер алдыннан гына 50 тоннага якын доллар кайтардылар дигән хәбәр күзгә чалынды берара, димәк, запаслар бар әле, тик аларны арзанга сатып бетермәячәкләр, билгеле. Үзәк банк, бәлки, интервенция ясап, валюта базарын бераз тотрыкландырырга тырышыр, әмма ул үзе дә санкцияләр астында. Валюта белән сәүдә итү мөмкинлеге берничә банкта калдырылды әлегә. Әгәр алар америкалылар куйган чикләрдән чыгып китмәсәләр, доллар сәүдәсе тукталмас, кыйммәт булыр, әлбәттә.

Үзәк банк үзе дә чит ил инвесторларының Россия кыйммәтле кәгазьләренә тыккан активларын «туңдырды». Тик аларның күбесе инде ул кәгазьләрдән котылып өлгерде, фонд базары бик каты түнде бит үткән атнада. Бар өмет, каршы якларның компромисска барып, үзара килешүләрендә. Шанслар кечкенә, әмма бар. Тик ул очракта да валюта базары бик югары бәяләрдә генә тотрыкланыр. Сумнар белән дә яшәп булачак. Базар бик ярлыланыр, билгеле. Элек җиңел генә алган нәрсәләрне табып булмас. Әмма тормыш дәвам итә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Узган ел нефть тармагында яхшы күрсәткечләргә ирешелгән. Бу ил күләмендә дә шулай. Аерым алганда, 2021 елда Татарстанда 34,5 млн тонна нефть чыгарганнар. Бу 2020 елдагы күрсәткечләрдән 5,8 процентка күбрәк. Республикада кичә нефть һәм аңа бәйле проектлар турында шактый сөйләштеләр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында «Татнефть» җәмгыятенең Директорлар советы утырышы узды. Очрашуда агымдагы елның гыйнвар ае бюджеты үтәлеше нәтиҗәләре каралды.

Бюджеттан тыш санлы мәгълүматларга килсәк, 2018 елдан 2021 елга кадәр компания запасларының үсеше планлаштырылган күләмнең 116 процент яки 123,2 млн тонна нефть һәм 6,1 млрд кубометр газ белән исәпләнә. Бу еллар аралыгында җир асты байлыкларыннан файдалану өчен 8 участок сатып алынган, Татарстанда булган икесен 2022 елда кулланышка кертләннәр инде.

Утырышта «Татнефть»нең экологияне кайгыртуга юнәлдерелгән проект нәтиҗәләрен дә телгә алдылар. Әйтик, климатка йогынты ясауны киметү өчен компания углерод эзен киметү буенча эш алып бара, өстәмә чара буларак агачлар утырта. Тулаем алганда, былтыр «Татнефть» 8 млн агач утырткан.

Хөкүмәт йортында кече нефть компанияләре дә узган елгы уңышлары турында хисап тотты.

Татарстан Президенты сүзләренчә, былтыр ил күләмендә 524 млн тонна нефть чыгарылган. 2020 елгы күрсәткечләрдән 2,2 процентка күбрәк дигән сүз бу. Татарстан да былтыргы күрсәткечләрен 5,8 процентка арттырып, 34,5 млн тонна «кара алтын» чыгаруга ирешкән. Шуның 27,4 млн тоннасы «Татнефть» компаниясенә туры килә. Кече нефть компанияләренә – 7,1 млн тонна. Бюджетка болардан 154 млрд сум акча кергән.

«Нефтеконсорциум МНК» җәмгыятенең баш инженеры Олег Вышенский чыгышыннан аңлашылганча, былтыр 23 кече нефть компаниясе нефть чыгаруга бәйле планны арттырып үтәгән, 276 яңа скважина файдалануга тапшырылган, тагын 150дән артыгы агымдагы елда сафка басачак.

Республика җитәкчесе кече нефть компанияләренең былтыргы эшчәнлеген югары бәяләде.

– Икътисадның ышанычлы эшләвен тәэмин итү – төп бурыч. Нефть сәнәгате – икътисад нигезе ул. Төзелеш, яңа технологияләр кертү, бораулау күләмнәре өлешендә билгеләнгән барлык бурычлар да планлы рәвештә үтәлергә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш бу көнне Рөстәм Миңнеханов катнашында «Татнефтехиминвест-холдинг» утырышы булды. Президентка берничә инновацион проект эшләре тәкъдим ителде. Алар арасында экологик авиаягулык җитештерү, органик пыяланың чыдамлыгын арттыру, пластмассаны икенчел куллану һәм башка файдалы тәкъдимнәр яңгырады. Президент аларның кайберләренә аерым тукталып, теләктәшлек күрсәтергә әзер булуларын әйтте.

tatarstan.ru

РАЙОН ҮСЕШТӘ

Эшлекле сәфәр

Менделеевск районы хисап сессиясендә узган елдагы эшчәнлеккә йомгак ясалды. Утырышта Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Моннан тыш парламент башлыгы капиталь төзекләндерелгәннән соң ачылган балалар сырхауханәсе һәм 3 нче урта мәктәптә булды.

Фәрит Мөхәммәтшинның эшлекле сәфәре республика үзәк хастаханәсенең балалар сырхауханәсе белән танышудан башланды. Сырхауханә республика программасы кысасында капиталь төзекләндерүдән соң ачылган. Парламент башлыгы табиблар белән аралашты. Алар сәламәтлек саклау өлкәсенә игътибар, яшь табибларга, аеруча бушлай җир кишәрлекләре белән ярдәм иткән өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт белдерде.

Парламент рәисе Менделеевскиның 3 нче урта мәктәбендә «Аммоний» акционерлык җәмгыяте ярдәмендә өр-яңа җиһазлар белән тәэмин ителгән химия, биология һәм физика кабинетларын карады. Озакламый мәктәп базасында химик-технологик лицей ачу күздә тотыла. Район җитәкчесе Радмир Беляев әйтүенчә, Казан технологик фәнни-тикшеренү институты (КХТИ) белән хезмәттәшлек турында килешүгә кул кую планлаштырыла.

Шуннан соң Фәрит Мөхәммәтшин Дмитрий Менделеевнның тууына 188 ел тулуга багышланган химия буенча муниципаль олимпиадада катнашучылар белән очрашты. Парламент башлыгы яшь химиклар белән әңгәмәсендә укучылар арасында олимпиада хәрәкәтенең бик мөһим булуын ассызыклады.

– Олимпиада – үз белемеңне күрсәтү өчен бик яхшы мөмкинлек ул, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Менделеевскида сезнең үсеш өчен барлык шартлар тудырылган. Районның ике зур предприятиесе ярдәмендә химия лицее ачыла. Ул кадрлар әзерләүнең беренче баскычы булып торачак. Бирегә педагоглар профориентация эше белән бик җитди шөгыльләнә. Мондый күренешне бик сирәк кенә очратырга мөмкин.

Менделеевск район советының чираттагы сессиясе Гассар исемендәге Мәдәният йортында узды. Район башкарма комитеты җитәкчесе Радмир Беляев районның 2021 елдагы социаль-икътисади үсеш йомгаклары һәм быелга бурычлары турында сөйләде. Аның әйтүенчә, 2021 елда Менделеевск районы социаль-икътисади үсеш рейтингында, 2020 елдагы белән чагыштырганда, 9 урынга өскә күтәрелеп, унынчы урынга чыккан. Тулай җирле продукт күләме 21,7 миллиард сум тәшкил иткән. Район 33,1 миллиард сум күләмендә товар җитештереп озаткан. Бу – алдагы елдагыга караганда 58 процентка күбрәк.

Радмир Беляев эшмәкәрлекне үстерүне алга китешле социаль-икътисади үсеш территориясенең (ТОСЭР) төп үсеш ноктасы буларак атап үтте. Биредә хәзер 15 компания эшчәнлек алып бара. Предприятиеләрдә 340тан артыграк кеше хезмәт куя. Менделеевск ТОСЭРда, Россиядә беренчеләрдән булып, 400 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән сөт продукциясе җитештерү буенча автоматлаштырылган экоферма булдырылган.

Авыл хуҗалыгында 658 миллион сумлык продукция җитештерелгән (узган елдагыга карата – 86 процент). Продукция җитештерүнең кимүе, Радмир Беляев әйтүенчә, җәйнең коры килүенә бәйле.

Фәрит Мөхәммәтшин, утырышка йомгак ясап, Менделеевск районының динамикалы төстә үсүен искәртте.

– Башкарма комитет җитәкчесе, үзенең чыгышында узган елдагы уңышларны телгә алып кына калмыйча, районның республика рейтингларында торган урынын көчәйтүгә һәм алга таба үсеш юлларын эзләүгә дә зур игътибар бирде, – диде ул. – Димәк, җитәкчелек эшчәнлек юнәлешен дөрес сайлаган. Менделеевск районы нык үсешле сәнәгатькә ия булып, үзенең авыл хуҗалыгы мөмкинлекләрен дә югалтмый. Соңгы вакытларда күп кенә күрсәткечләр сизелерлек яхшырган. Дөрес, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү берникадәр аксый әле. Әмма республика җитәкчелеге ярдәмендә Менделеевск бу мәсьәләне хәл итәр дип уйлыйм.

«Алло» диюдән башлана

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ят номерга түгел, телефонга шалтыраткан таныш номерга да ышанмаслык чорда яшибез. Ник дигәндә, мошенниклар соңгы арада номер алмаштыру белән дә мавыга. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм иҗтимагый элемтәләр бүлеге башлыгы урынбасары Максим Костромин сүзләренә караганда, кырыгалдар, гадәттә, бер номердан шалтырата, ә кешегә ул теге яки бу орган, оешманың номеры булып күренә.

– Шуңа күрә телефон кырыгалдарлары корбаны булмас өчен иң элек 112 номерына яки «ышаныч телефоны»на шалтыратып, теге яки бу номер буенча кемнең шалтыратуын, ул сөйләгән сүзләрнең дөресме-юкмы икәнлеген белешергә кирәк. Шикле номерны шалтыратып тикшерергә уйлаган очракта, аңа телефон кенәгәсендә күренгән номерга басып кына түгел, ә шул ук саннарның һәркайсын яңабаштан җыеп шалтыратырга кирәк. Ник дигәндә, әзер номерга гына шалтыраткан очракта сез барыбер аның артына яшеренгән мошенник номерына шалтыратачаксыз, – ди Максим Костромин.

Телефон аша эш итүче мошенниклар корбаны булмас өчен хокук сакчылары тагын берничә кагыйдәне истә калдырырга киңәш итә. Беренчедән, банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчаңны югалта аласың, дип куркытып шалтыратмый. Алар клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләр дә сорамый. Гомумән, үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны беркемгә дә хәбәр итмәгез. Банк хезмәткәре башта кредит рәсмиләштереп, аннары шуны ниндидер билгесез счетларга күчерүне сорый икән – шулай ук шикләнергә җирлек бар. Сезгә чынлыкта кемнең шалтыратуын банкның «кайнар элемтәсе»нә шалтыратып белешегез. Аның номеры банк картасының арткы ягында күрсәтелә. Эчке эшләр органнарына да мөрәҗәгать итү комачауламас.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӘБЕСТӘ – АЛДАН, ЙОМЫРКА АРТТАН ЙӨГЕРӘ

Россиядә азык-төлек бәяләрен йөгәнләү юлларын эзлиләр. Социаль әһәмияттәге товарларга бәя арттыруны чикләргә мөмкинлек бирә торган закон проекты Дәүләт Думасына кертелгән. Яңа закон быелның 1 сентябреннән эшли башларга мөмкин. Әлеге категориягә ипи, шикәр, эремчек, атланмай һәм башка азык-төлек төрләре керә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, кибеттәге товарларның бәяләре оешмалар, сату нокталары һәм арадашчылар куйган хаклардан формалаша. Белгечләр әйтүенчә, кайвакыт мондый өстәмә бәяләр хәтта 100 процентка кадәр җитә. Россиянең Монополиягә каршы федераль хезмәте мәгълүматларына караганда, сәүдә нокталары яшелчәләрнең бәяләрен 50 процентка кадәр арттыра.

Әлеге мәсьәлә икмәк пешерүчеләрне дә борчый. Казанның күмәч-кондитер комбинатының («БКК» җәмгыяте) генераль директоры Булат Котдусов сүзләренчә, кибеттәге ипи бәяләрен чамадан тыш арттыралар. Ул бу аерманы 25–60 процент дисә, Кукмара районы эшмәкәре Рамазан Юнысов кайбер кибетләр бәяне хәтта 120 (!) процентка кадәр күтәрә дигән фикерен җиткерде.

– Без үзебезнең икмәкләребезне эре кибетләр челтәренә кертү турында уйлана башлаган идек, – ди Рамазан Юнысов. – Ләкин шартлары белән таныша башлагач, чәчләр үрә торырлык. Бердән, таләпләре бик катгый. Икенчедән, бәяләр. Алар безгә шушы бәяне 30 процентка төшерергә тәкъдим иттеләр. Безгә болай да җиңел түгел. Ул вакытта без батонны 25 сумнан җибәрә идек. 17 сум 50 тиеннән бирергә кушалар. Ә нәкъ шушы батон үзләренең кибетләрендә 39 сум 90 тиен тора. 120 (!) процентка арттырып саталар бит! Бу башка сыя торган әйбер түгел.

Чыннан да, соңгы 1–1,5 елда азык-төлек бәяләре арту иң актуаль темаларның берсенә әйләнде. Илкүләм банк (Нацбанк) мәгълүматлары буенча, Татарстанда гыйнварда еллык инфляция 8,9 процентка кадәр җитте. Белгечләр әйтүенчә, яшелчә һәм җиләк-җимешкә ихтыяҗ кими, бизнес авырлык кичерә. Кәбестәгә көннән-көн бәя артуны әнә шуның белән аңлаталар. Соңгы айда шулай ук сөт, сыр һәм атланмай, груша, лимон һәм виноград бәяләре арткан. Моның сәбәбен таможня тикшерүләренең озакка сузылуы һәм чит илдән кертелә торган җиләк-җимешләрнең тоткарлануы белән аңлаталар. Ә менә йомырка һәм ит бәяләре барыннан да акрынрак үсә икән.

Болардан кала, Мәскәү сәүдә-сәнәгать палатасының эшмәкәрлекне үстерү буенча комитет башлыгы урынбасары Марина Петрова баллы ризыкларга бәя артуын да билгеләп узган. Аның сүзләренчә, бу мәсьәләдә Татарстан хәтта гомумроссия күрсәткечләрен узып киткән.

Шулай итеп, республикада шоколад кәнфитләрнең бәяләре 9 процентка кадәр күтәрелгән. Зефир һәм как – 17, кекс һәм рулетлар 18 процентка арткан. Шул ук вакытта илдә әлеге ризыкларга бәяләр акрынрак үсә.

Бәяләр артып торганлыктандырмы, узган ел россиялеләр кондитер ризыкларын азрак кулланган. 2021 елда бу күрсәткеч 7–10 процентны тәшкил иткән.

– Без бәяләрне истә дә калдыра алмыйбыз, чөнки алар айлап түгел, көнләп үзгәрә, – диде безгә Казан кибетендә ипи-батон, кондитер ризыклары сатучы Надежда Дунаева. – Мәсәлән, атланмай кушып пешерелә торган печеньеның бер килограммы бүгенгә 515 сумга җитте. Әле кайчан гына ул 300 сум тирәсендә иде. Башка төр печеньелар да артып тора. Аларның килограммнары уртача алганда 300–350 сум тирәсендә тирбәлә. Бәяләре иң еш артып тора торган ризыклар исемлегендә ипи, батон, сөт, сыр, чәй, атланмай тора. Халык арасында иң зур ихтыяҗ казанган товарлар да шулар.

Болай да өскә үрмәләргә генә торган бәяләр соңгы вакыйгалар тәэсирендә тагын да иреккә чыкты. Кайбер ритейлерлар, вазгыятьне үз файдаларына кулланып, бәяләрне бермә-бер арттырды. Әлеге хәлләргә Россия Премьер-министры Михаил Мишустин да игътибарын юнәлтеп, социаль әһәмияткә ия булган продуктларга бәяләрне тикшерергә кушты. Хөкүмәт башлыгы фикеренчә, бүгенгә иң мөһим темаларның берсе – азык-төлек бәяләре.

– Агросәнәгать комплексы үз товарларын җитештерүне үстерү буенча күп кенә проектларны актив рәвештә тормышка ашыра. Һәм, әлбәттә, боларның барысын да күзәтеп, тикшереп торырга кирәк, – диде Михаил Мишустин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктчада:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«транспорт чараларына тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган гавами файдаланудагы стационар автомобиль ягулык салу станциясе (тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган катнаш ягулык автомобиль ягулык салу станциясе, автомобиль газ тутыру компрессор станциясе, тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган криоген автомобиль ягулык салу станциясе) төзелешенә кимендә 70 миллион сум;»;

б) өченче – алтынчы абзацларны тиешенчә дүртенче – җиденче абзацлар дип санарга;

2) 5 пунктчаның дүртенче абзацында «Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешле төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компания турында һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 4-ТРЗ

Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә хокукый җайга салу**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә хокукый җайга салу «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итү;

2) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп тору;

3) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) федераль дәүләт хакимияте органы белән берлектә Татарстан Республикасы территориясендәге җир асты байлыклары дәүләт фонды белән эш итү, моңа бары тик Россия Федерациясе карамагында гына булган җир асты байлыклары кишәрлекләре керми;

3) Россия Федерациясе җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минерал-чимал базасын үстерү һәм үзләштерү буенча дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

4) минерал-чимал базасын үстерү һәм алардан файдалану буенча территориаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

5) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минерал-чимал базасын торгызу һәм җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыручы башкарма органын (алга таба – Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы) билгеләү;

7) иясе Татарстан Республикасы булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгеләү;

8) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы белән берлектә гомумтаралган файдалы казылмаларга карый торган файдалы казылмаларның республика исемлеген әзерләү һәм раслау;

9) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән (алга таба – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре) файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында каралган нигезләр буенча бирү тәртибен билгеләү;

10) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы су һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү (алга таба – эчәргә яраклы су белән тәэмин итү) яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалануга бирү тәртибен билгеләү;

11) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен билгеләү;

12) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы белән үзләренә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне яисә берләштерелгән лицензия буенча авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне, шундый файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан үзләренең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны расланган техник проект нигезендә чыгару тәртибен билгеләү;

13) җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендага алучыларның үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен билгеләү;

14) коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында әлеге ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару тәртибен билгеләү;

15) минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекцион материаллар җыю өчен җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы бирү турында җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештерелгән карарлар кабул итү;

16) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

17) Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның хокукларын һәм гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау, җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү;

18) Россия Федерациясе Конституциясендә һәм федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы исеменнән җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда продукция бүлешү турындагы килешүләрдә катнашу;

19) файдалы казылмалар чыганакларыннан файдалану шартларын билгеләүдә катнашу;

20) региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау;

21) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештереп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген әзерләү һәм раслау;

3) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү турында һәм аукцион комиссияләренең составы хакында карарлар кабул итү;

4) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт контрактлары төзү;

5) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органына яисә аның территориаль органына җир асты байлыклары кишәрлекләрен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен, берләштерелгән лицензия буенча гамәлгә ашырыла торган җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертү турында, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү шартлары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр шартлары турында тәкъдимнәр кертү;

6) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү;

7) җир асты байлыкларыннан файдалануның «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 6 статьясында каралган төрләре буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану шартларын әзерләү;

8) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын ачу фактын билгеләү буенча составына җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы вәкилләре керә торган комиссия төзү;

9) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштергәндә яисә яңадан рәсмиләштергәндә җибәрелгән техник хаталарны (сүзне бозып язу, ялгыш басу, грамматик яисә арифметик хаталарны яисә шундый башка хаталарны) төзәтү;

10) җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләмен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга тиешле тәртиптә лицензия бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр кишәрлеге буенча аерым билгеләү;

11) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 10^1 статьясындагы беренче өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән максатларда җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы бирү турында гаризаларны карау өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

12) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 23^2 статьясының өченче өлешендә каралган авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүгә проект документациясен, шулай ук күрсәтелгән проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрне килештерү буенча җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

13) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда туктату, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын чикләү тәртибен билгеләү;

14) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын чикләү буенча комиссия төзү;

15) Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын булдыру һәм алып бару;

16) файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрнең дәүләт реестрын алып бару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләргә карата белешмәләр бирү;

17) файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасында катнашу;

18) файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмый торган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү;

19) гомумтаралган файдалы казылмалар запасларының республика балансын һәм аларның чыганаклары һәм чагылышлары республика кадастрын төзү һәм алып бару, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган корылмалар төзү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу;

20) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын, радиоактив калдыкларны, I – V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклау корылмаларыннан тыш (алга таба – файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмалары), төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү;

21) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләре кишәрлеген бүлеп бирүнең төгәлләштерелгән чикләрен тикшергән документларны (тау эшләре кишәрлеге акты һәм график кушымталар) рәсмиләштерү;

22) региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

23) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә түбәндәгеләр керә:

1) гомумтаралган файдалы казылмалар булган җир асты байлыклары кишәрлекләре;

2) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм аларның яраклы булуын бәяләү өчен файдаланыла торган һәм (яисә) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре;

3) эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты сулары булган җир асты байлыклары кишәрлекләре.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген әзерләү һәм раслау, җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештереп, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү нигезләре**

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органының Татарстан Республикасы законнары нигезендә түбәндәгеләр турында кабул ителгән карары:

а) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм аларның яраклы булуын бәяләү өчен һәм (яисә) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

б) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эзләү һәм бәяләү өчен гомумтаралган файдалы казылмалар чыганагы булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачык чыганакның табылу факты билгеләнгәндә, мондый җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык чыганактагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен файдалану хокукын бирү турында, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контракты нигезендә җир асты байлыкларының бу кишәрлеген геологик өйрәнү гамәлгә ашырылган очракта, җир асты байлыклары кишәрлеге моңа керми;

в) файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска вакытлы (бер елга кадәр) файдалану хокукын бирү турында;

г) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

д) җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны разведкалау һәм чыгару максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

е) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында;

ж) коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

2) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан төзелә торган аукцион комиссиясенең файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү турында, ә «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 13^1 статьясындагы сигезенче өлешендә каралган очракта, әлеге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын гаризасы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы таләпләренә һәм игълан ителгән аукцион шартларына туры килә торган затка яки аукционның бердәнбер катнашучысына бирү турында карары;

3) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органының җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештерелгән һәм минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекцион материаллар җыю өчен кабул ителгән карары;

4) продукция бүлешү турында «Продукция бүлешү турында килешүләр хакында» 1995 елның 30 декабрендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешү;

5) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә карата «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан төзелгән дәүләт контракты.

8 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән әлеге Законның 7 статьясындагы 1, 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча файдалану хокукы аукцион үткәрмичә генә бирелә.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына мондый хокук алу өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр кушымта итеп тапшырылган гаризаны (алга таба – гариза) карау нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

3. Гариза һәм аңа кушымта итеп тапшырыла торган документлар һәм белешмәләр алынганнан соң 20 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы мөрәҗәгать итүчегә әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында яисә гаризаны кабул итүдән баш тарту хакында карар кабул итә, гариза бирүчегә бу хакта тиешле карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә хәбәр итә.

4. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү тәртибе, гариза формасы, гаризага кушымта итеп бирелә торган документларның һәм белешмәләрнең тулы исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирү «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән әлеге Законның 7 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча файдалану хокукы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә үткәрелә торган аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион үткәрү турында, тиешле аукцион комиссиясе составы хакында карар Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан кабул ителә.

3. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге)**
1. Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты расладан нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.
2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата региональ дәүләт геология контроленең (күзәтчелегенең) предметы җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Су кодексында (җир асты су объектларын саклау таләпләр өлешендә), Россия Федерациясе Салым кодексында (файдалы казылмалар һәм җир асты су объектларын чыгарганда югалту нормативлары өлешендә) һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрдә һәм күрсәтелгән норматив хокукый актларда каралган башка рөхсәт документларында булган таләпләрнең оешмалар һәм гражданнар тарафыннан үтәлешеннән гыйбарәт.
3. Үтәлеше региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) кысаларында бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр кертелгән рөхсәт документларының исемлеге региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәдә күрсәтелә.
4. Региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

11 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**
Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:
1) «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12);
2) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2);
3) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2001 елның 21 ноябрендәге 1193 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 12);
4) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 23 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7);
5) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 8 апрелендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш);
6) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 мартындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3);
7) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 октябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10);
8) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);
9) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2012 елның 14 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);
10) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 28 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш);
11) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 1 – 2);
12) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 11 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 4);
13) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 14 маендагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);
14) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш);
15) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 2 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 7 (I өлеш);
16) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 3);
17) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш);
18) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 16 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш);
19) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 ноябрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 92 (I өлеш);
20) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 358.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июлендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш);
21) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 4 июлендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 51 (I өлеш);
22) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 11 декабрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 94 (I өлеш);
23) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 11 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш).

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 5-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья
Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составы Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә билгеләнә.»;
2) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан, крестьян (фермер) хуҗалыклары үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалана торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы җир кишәрлекләрендә торак йортлар төзү, реконструкцияләү һәм куллану рөхсәт ителми.».

2 статья
«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 1 статьяның 1 пунктын юкка чыгарырга;
2) 2 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

3 статья
1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясы 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 6-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 10 февралендә кабул ителде

1 статья
«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 7 статьяның 3 пунктында «, шул исәптән дәүләт юридик бюросын гамәлгә кую һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү турындагы мәсьәләләрне хәл итү» сүзләрен өстәргә;
2) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) дәүләт юридик бюросы.»;
3) түбәндәге эчтәлекле 10^{1} статья өстәргә:
«10^{1} статья. **Дәүләт юридик бюросы тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**
1. Гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән дәүләт юридик бюросы төзелергә мөмкин.
2. Дәүләт юридик бюросы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе рәвешендә төзелә.
3. Дәүләт юридик бюросы әлеге Законның 4 статьясында каралган түләүсез юридик ярдәмнең барлык төрләрен дә күрсәтә.»;
4) 12 статьяда:
а) 2 өлешнең беренче абзацында «адвокатлар» сүзен «дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 өлешнең беренче абзацында «адвокатлар» сүзен «дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;
5) 14 статьяда:
а) 3 өлештә «дәүләт органнарына» сүзләрен «дәүләт юридик бюросына» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 өлештә «Вәкаләтле дәүләт органнары һәм дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар» сүзләрен «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;
6) 17 статьяның 1 өлешендә «бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары,» сүзләреннән соң «дәүләт юридик бюросы,» сүзләрен өстәргә;
7) 18 статьяның 2 өлешендә «түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче» сүзләреннән соң «дәүләт юридик бюросын төзүгә һәм аның эшчәнлегенә һәм» сүзләрен өстәргә.

2 статья
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 7-ТРЗ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының оператив-эзләү (шәхси куркынычсызлык) часте башлыгы, полиция полковнигы **Галләмов** Марсель Нафил улына; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы эксперт-криминалистика үзәге башлыгы, полиция полковнигы **Мөхәммәтҗанов** Әнәс Харис улына; Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе юл-патруль хезмәте полкы 1 нче батальонының 2 нче ротасы 2 нче взводы өлкән инспекторы, полиция өлкән лейтенанты **Карама** Илдар Әсхәт улына; «Тормыш эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Юл хәрәкәте иминлеге» бүлеге башлыгы **Попов** Валерий Николаевичка; «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесе госпитале башлыгы урынбасары – госпиталь (Чаллы шәһәрендә урнашкан) табибы **Камалова** Вәсилә Әхмәт кызына; «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең баш инженеры-энергетигы **Арсланов** Илнур Кайсар улына; «Татнефтепровод строй» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Демидов** Иван Петровичка; «Яңа тормыш» акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры **Закиров** Илсур Мансур улына; Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенең Чаллы шәһәрендә күзәтчелек бүлеге баш дәүләт хезмәт инспекторы **Булычов** Эдуард Сергеевичка; Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенең хезмәтне саклау бүлеге башлыгы **Зәйнетдинова** Алсу Хәмит кызына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлеге өлкән белгече **Әхмәтова** Венера Нәҗип кызына; «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Эзләү-коткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесенең 7 номерлы зона эзләү-коткару отряды (Лениногорск) коткаручысы **Гронзель** Евгений Викторовичка; Башкортстан Республикасы Татар хатын-кызларының социаль статусын күтәрү «Сәхибҗамал» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Усманова** Рәфига Кәрам кызына; Татарстан Республикасы Арбитраж суды судьясы **Аверьянов** Михаил Юрьевичка; Татарстан Республикасы Арбитраж суды судьясы **Галиева** Юлия Нариман кызына; Татарстан Республикасы Арбитраж судының мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы урынбасары **Сундырцева** Татьяна Алексеевнага, хезмәт ветераны **Трескин** Эдуард Германовичка; «Республиканың матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Буа муниципаль районындагы 15 номерлы бүлекчәсе мөдире **Дроздова** Юлия Александровнага; Бөгелмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының хисап һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары **Жидкова** Ольга Александровнага; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының лицензияләү бүлеге әйдәүче белгече **Хәсәнова** Эльмира Габдрахман кызына; Бөгелмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе урынбасары – бюджет бүлеге башлыгы **Шаталова** Людмила Степановнага; «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе башкарма директоры – оешманың Аппараты җитәкчесе **Какохо** Тимур Геннадиевичка; Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының җыелма-аналитика бүлеге башлыгы **Фадеева** Татьяна Александровнага; Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсендәге төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары **Хәйретдинов** Рушан Әсгать улына; Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Норкрат баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банкның хуҗалык-эксплуатация бүлеге матди-техник тәэминат секторы әйдәүче эксперты **Халитова** Гөлфия Адил кызына; Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының машиналар төзү комплексы бүлеге башлыгы **Хәсәнова** Эльмира Радик кызына; Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе укытучысы **Әхмәтгалиева** Фирдәүс Миргасыйм кызына; Хөсәен Әхмәтов исемендәге Башкорт дәүләт филармониясе Башкортстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният һәм сәнгать учреждениесе музыкаль-әдәби лекторие лекторы-сәнгать белгече (музыка белгече) **Әюпова** Венера Хәдис кызына; Уфа шәһәренең Киров районы «Ихлас» мөселман дини оешмасы телестудиясенең баш инженеры **Еникиев** Илдар Рифгать улына; «Мегион шәһәренең «БОЛГАР» татар милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Кыямов** Рамил Рәсим улына; Удмуртия Республикасы татарларының милли-мәдәни мохтарияте төбәк иҗтимагый оешмасы советы әгъзасы **Миңнемуллин** Илсур Гафиулла улына; «ИНЕС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең гамәлгә куючысы **Суфияров** Альберт Диас улына; Нижневартовск шәһәренең «Мирас» татар милли-мәдәни мохтарияте иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Вагыйзов** Наил Вакыйф улына; «Татспецтранспорт» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Баулы технологик транспорт идарәсе эксплуатация бүлеге башлыгы **Галиев** Фәрит Зәкәрия улына; «Техно Транс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте башкарма директоры **Матвеев** Олег Николаевичка; Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы **Зиннәтуллин** Габбас Габделхәй улына; Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе урынбасары **Маслова** Ольга Александровнага; «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Таһиров** Рафикъ Рөстәм улына; Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Трофимова** Марина Дмитриевнага; «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Дербышки бүлеге башлыгы **Фәхретдинова** Ильвира Рафикъ кызына; «Кама инновация территориаль-җитештерү кластеры» коммерциячел булмаган партнерлыгы» ассоциациясе вице-президенты **Әбҗәлилова** Ләйсән Рәхим кызына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек секторы баш киңәшчесе **Ишниязов** Альберт Сингатулла улына; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе административ хокук һәм законнарны системалаштыру секторы мөдире **Кознова** Клавдия Анатольевнага; Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Социаль-икътисади мониторинг департаменты муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисади хәлен мониторинглау бүлеге башлыгы **Куличкова** Миләүшә Мөбарәк кызына; «Фәнни-техник өлкәдә предприятиеләрнең кече формаларын үстерүгә булышлык фонды» федераль дәүләт бюджет учреждениесе генераль директоры урынбасары **Микитась** Андрей Владимировичка; «ВЭБ.РФ» үсеш дәүләт корпорациясенең шәһәр чишелешләре һәм моношәһәрләрне үстерү блогы директоры **Савон** Аурика Васильевнага; «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – икътисад һәм финанслар буенча директоры **Сафиуллин** Илшат Илдус улына; «Эфир» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Яхина** Гөлсия Фидаил кызына; «Спадчына» («Мирас») Казан шәһәрендә яшәүче белорусларның җирле иҗтимагый оешмасы рәисе **Маруденко** Сергей Павловичка; «Татарстан Республикасының яһүд милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе **Скоблионок** Михаил Абрамовичка; нефть сәнәгате ветераны **Мансуров** Рәзиф Рәшит улына; «Стройгазпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәйруллин** Рәис Разак улына; Татарстан Республикасы хәрби комиссары урынбасары, полковник **Денькин** Алексей Юрьевичка; «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан Суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесенең уку-укыту бүлеге педагог-психологы **Сәрвәров** Альберт Юдис улына; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының баш тикшерү идарәсе оешкан җинаятьчел эшчәнлекне тикшерү часте (идарә хокуклары бирелгән) икътисад өлкәсендә оешкан җинаятьчел эшчәнлекне һәм коррупциячел җинаятьләрне тикшерү бүлеге башлыгы, юстиция подполковнигы **Хәсәнов** Рамил Ринат улына; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы **Зарипов** Илдус Фатыйх улына; җәмәгать туклануы системасын үстерүгә һәм халыкка югары сыйфатлы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Аш-су» кулланучылар җәмгыяте коллективына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Вәлиев** Марс Имаметдин улы; эшендә уңышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «ФБК Поволжье» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Никифоров** Сергей Леонидович; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Чит телләр һәм тәрҗемә югары мәктәбенең тәрҗемә теориясе һәм практикасы кафедрасы профессоры-консультанты **Ратнер** Фаина Лазаревна; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды суд составы рәисе **Сибгатуллина** Луиза Илфат кызы; республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең билбаулы көрәш буенча тренеры **Сөләйманов** Бари Равил улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Хәкимҗанов** Сәетҗан Газим улы; илебезнең очкычлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләре: баш конструктор – конструкторлык бюросы бүлеге башлыгы **Галәвиев** Илшат Рашат улы, җыюны төгәлләү цехының очкыч аппаратлар слесаре-җыючысы **Ивойлов** Сергей Александрович, сынау очышлары станциясенең инженерлык-авиация хезмәте башлыгы **Колесов** Дмитрий Владимирович, Ту-160 агрегат-җыю производствосының җыючы-чүкеп беркетүчесе **Кукаркин** Валерий Александрович, баш технологның махсус технология процесслары буенча урынбасары **Мансветов** Сергей Николаевич, «70» эшләнмәсен төзекләндерү һәм яңарту производствосының очкыч аппаратлар слесаре-җыючысы **Маслов** Анатолий Анатольевич, «70» эшләнмәсен төзекләндерү һәм яңарту производствосының җыючы-чүкеп беркетүчесе **Николаев** Руслан Валерьевич, сынау очышлары станциясенең һава судноларын эксплуатацияләү буенча инженеры **Нугаев** Илдар Нияз улы, механик пресс, калыплаштыру детальләре һәм нормальләр цехы шомартучысы **Фәсхиев** Ахияр Шаһи улы, механик пресс, калыплаштыру детальләре һәм нормальләр цехы инженер-технологы **Хәлиуллина** Нурания Зиннур кызы, гидроагрегатларны механик җыю цехының механик җыю эшләре слесаре **Хөснуллин** Вәлиулла Хазимулла улы, Ту-160 агрегат-җыю производствосының очкыч аппаратлар слесаре-җыючысы **Шадрин** Юрий Аркадьевич; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада автомобиль спортын популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасының Автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры **Баһаутдинов** Рафаэль Риф улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе **Гарипов** Рәшит Мөхәммәтдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Сафиуллова Рима Гомәр кызы» крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Куприянов** Геннадий Анатолиевичка, «Уңыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Ютазы районы) **Мәҗитов** Фәнил Камил улына; «Афзалов Марат Ринат улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Нургалиев** Фирдәвес Гыйльмегаян улына; «САРМАН» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты **Сәгъдәтов** Ринат Флер улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының гомуми бүлеге башлыгы **Баев** Насыйх Зәет улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кадрлар бүлеге әйдәүче белгече **Бикмуллин** Рәшит Гомәр улына, Тимирязев исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Исрафилов** Булат Сәйдәш улына, «Кызыл Шәрык Агро» акционерлык җәмгыятенең «Юхмачы» терлекчелек комплексы идарәчесе (Татарстан Республикасының Әлки районы) **Кәримов** Марат Рәшит улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кече хуҗалыкларны үстерү бүлеге башлыгы **Молокин** Александр Николаевичка, «Сәетов Илнур Рафис улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) **Сәетов** Илнур Рафис улына, «Новая Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш икътисадчысы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Салихова** Миләүшә Гаяз кызына, «Ташкын» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бухгалтеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Солтанова** Алсу Әксән кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Халитов** Тәлгать Әхмәтсафа улына, «Хисмәтуллин Мансур Зиннәтулла улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Хисмәтуллин** Мансур Зиннәтулла улына, «Ташкын» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бригадиры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Шамсов** Рил Риф улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«СТРОИ-ТЕХНОЛОГИЯ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Кәримов** Илдар Әүхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Илебездә очкычлар төзү тармагын үстерүдәге зур казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен идарәче директорның беренче урынбасары – «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы директоры **Савицких** Николай Владимирович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Илебездә очкычлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Туполев» гавами акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводының «70» эшләнмәсен төзекләндерү һәм яңарту производствосы участок мастеры **Ключникова** Ольга Вячеславовна **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга мөһим өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция полковнигы **Гатцук** Евгений Николаевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Абзалов** Рифкать Нургали улы; **Мөхәммәтов** Җәмил Мөхәммәт улы; **Назаров** Александр Ефимович; Хәйруллина Нурия Габбаз кызы; **Хәсәнов** Әгъләм Әдһәм улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Эйдлин** Григорий Пеничка **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, генераль директор аппараты җитәкчесе **Мухин** Владимир Сергеевичка, «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте башкарма директорының металл кою производствосы буенча урынбасары – металл кою заводы директоры **Панфилов** Эдуард Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«РМ АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең логистика бүлеге автомобиль йөртүчесе **Еремеев** Анатолий Васильевичка, «Инвестпромдорстрой-НЧ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Левашов** Михаил Григориевичка, Идел буе федераль округы буенча автомобильдә йөк ташучылар халыкара ассоциациясе филиалы Идел буе федераль округы буенча автомобильдә йөк ташучылар халыкара ассоциациясенең Казан шәһәрендәге вәкиле **Линдваль** Александр Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЕШЕ

Рөстәм Миңнехановка – 65 яшь. «ВТ» Татарстан Республикасы Президенты турында халык фикерләрен туплады.

«АНЫҢ АБРУЕ ЗУР»

Марат БӘШӘРОВ,
сәясәт белгече (Мәскәү):

Рөстәм Миңнеханов – Россия Федерациясендәге иң тәҗрибәле җитәкчеләрнең берсе. Татарстан Президенты вазыйфасында ул башкарган эш республикага ышанычлы рәвештә үсәргә, социаль-икътисади сәясәтне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Ә бу – гади кешенең тормышын кайгырту дигән сүз. Әлеге вазыйфада ул әзлеклелекне саклап, озак еллар Минтимер Шәймиев башкарган эшне дәвам итә.

Рөстәм Миңнехановның төбәк җитәкчеләре арасында да абруе зур. Билгеле булганча, ул Россия Дәүләт Советының Төзелеш, ТКХ һәм шәһәр мохите комиссиясен, илнең инновацияле төбәкләр ассоциациясен җитәкли. Сер түгел, төбәк башлыклары арасында яшь җитәкчеләр дә бар. Аларга үрнәк алырлык кеше кирәк. Рөстәм Миңнеханов исә тәҗрибә белән бик теләп уртаклаша.

Кешелеклелек сыйфатлары булу белән бергә Рөстәм Миңнеханов Татарстан өчен мөһим булган мәсьәләләрдә ныклы фикерен әйтә белә. Республика мәнфәгатьләрен дә, ил мәнфәгатьләрен дә исәптә тотып эшли.

Рөстәм Миңнехановның илдә генә түгел, халыкара мәйданда да абруе зур булуын билгеләп үтми мөмкин түгел. Республикада чит ил делегацияләре еш була, ул үзе дә халыкара эшчәнлектә актив катнаша. Татарстан Президенты Россиянең ислам илләре белән мөнәсәбәтләрендә зур роль уйный, төрки дөнья белән элемтәләр җайга салынган. Бу – бик мөһим мәсьәлә. Чөнки татарлар – зур төрки дөньяның бер өлеше. Бу халыкларның үзара дустанә яшәве бик мөһим. Татарлар күпмилләтле Россиянең тормышында да зур роль уйный. Без, татарлар, үзебезнең тынычлыкка, үсешкә омтылуыбызны күрсәтергә тиеш. Рөстәм Миңнеханов әнә шундый сәясәт алып бара.

«БЕЗ АННАН ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ»

Илдус ДӘҮЛӘТОВ,
эшмәкәр, Оренбург өлкәсе татар автономиясе җитәкчесе, Оренбург законнар чыгару җыены депутаты:

Мин үзем Оренбург өлкәсендәге Әсәкәй авылында фермер хуҗалыгын җитәклим. Татарстанга юлыбызның өзелгәне юк, чөнки безне монда аңлыйлар, киңәш бирәләр, ярдәм кулы сузалар. Бу очракта мин бигрәк тә Президентыбыз Рөстәм Миңнехановны күздә тотам. Арттырып әйтүем түгел, без аны фәрештәгә тиңлибез, аннан яшәргә өйрәнәбез. Бер карасаң, гаҗәп бит: нинди катлаулы вазыйфаны алып бара, ә үзе бөтен кеше белән аралашырга өлгерә. Бервакыт ул: «Үз сүзеңне әйтергә трибуна булсын өчен, сиңа депутат булырга кирәк», – дип киңәш бирде. Шулай иттем да. Оренбург Законнар чыгару җыенында инде дүртенче чакырылышка депутат булып сайландым. Өлкә буенча татар автономиясен җитәклим. Рөстәм Нургалиевичның гадилегенә кайчак гаҗәпләнеп тә куям. Без аның белән гел элемтәдә, телефоннан сөйләшеп торабыз. Трубканы алырга уңайсыз вакыт булса, үзе соңыннан шалтыратмый калмый. Ә үзебезнең губернатор белән андый ук мөнәсәбәтләр тудырып булмады. Шуңа күрә, үзебезнең Президентыбыз бар дип, рәхәтләнеп, горурланып яшибез. Чыннан да, Рөстәм Нургалиевич – Татарстан өчен генә түгел, бөтен татар халкы өчен Президент. Икътисадны үстерүгә дә зур әһәмият бирә. Татар эшмәкәрләрен җыеп, ел саен сөйләшүе – шуның бер дәлиле. Аның мөнәсәбәте уңай булгач, җирле җитәкчеләр дә безнең белән санлашырга мәҗбүр. Җәй туры килгән саен, Татарстанны үрнәк итеп куябыз. Мәсәлән, мин Җыенда чүп белән эш итүгә бәйле программа турында сөйләп чыккан идем. Хәзер инде өч ел Татарстан үрнәгендә эш алып барабыз. Мәктәпләрдә балалар татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыйлар. Мәдәни чаралар да татарча үтә. Татарстан ярдәме белән чын татар булып яшибез.

Форсаттан файдаланып, Президентыбызга читтә яшәүче татарлар исеменнән зур рәхмәтләребезне җиткерәбез, туган көне белән котлыйбыз. Һәрбарчабызга исәнлектә, иминлектә яшәргә язсын.

«БЕЗДӘ ЯХШЫ УКЫР ӨЧЕН БАРЛЫК МӨМКИНЛЕКЛӘР БАР»

Алмаз ХӘМИДУЛЛИН,
Казандагы «Унбер» лицее директоры:

Һәр илнең үсеше мәгарифтән, кеше капиталын үстерүдән башлана. Рөстәм Миңнеханов моны яхшы аңлый, шуңа күрә мәгариф тармагына аеруча игътибар бирергә тырыша. Ел саен республикада заманча бакчалар, мәктәпләр ачыла.

2019 елдан «Адымнар» полилингваль белем бирү комплекслары проекты тормышка ашырыла. Ул рус, татар һәм инглиз телләрендә көндәшлеккә сәләтле белем бирүне күздә тота. Казанда, Алабугада, Чаллыда, Актаныштa дүрт комплекс эшләп килә. Тиздән Түбән Камада һәм Әлмәттә дә ачылачак. «Унбер» мәктәбе федераль программа буенча төзелсә дә, республика да үз өлешен кертте. Халыкара дәрәҗәдәге мәктәп бу, бездә яхшы укыр өчен барлык шартлар тудырылган. Укытучылар арасында Санкт-Петербург, Бөекбритания, Казахстан, Америка, Колумбиядән килгән мөгаллимнәр дә бар. Укучылар лабораторияләрдә фән белән дә шөгыльләнә ала.

Республикада олимпиадада катнашучылар өчен грантлар булдырылган. Шул ук вакытта укытучыларны мәктәпләргә беркетү, педагогик уку йортларына максатчан кабул итү, яшь укытучыларга ярдәм итү, торак шартларын яхшырту буенча да эш алып барыла. Педагогик вузларда максатчан программа буенча белем алучы студентларга ай саен 15 мең сум стипендия түләнә. «Безнең яшь укытучы» дигән бик яхшы программа бар. Болар барысы да – республика җитәкчесе эшчәнлеге нәтиҗәсе.

«УЛ – ЧЫН ТАТАР БЛОГЕРЫ»

Ринат ГАЛИӘХМӘТОВ (@tatar_malay), блогер:

Аңа карап блогер булдым, дисәк тә була. Хикмәт шунда: 2013 елда Рөстәм Миңнеханов «Инстаграм»да блогын ачты. Шуннан карап, мин дә ачтым. Ул чакта әле @tatar_malay түгел идем. Кушымтаны нәкъ менә Президент аша белдем. Шуннан соң ике ел алып барып, әйрәнеп, блогер булдым.

Президентның блогы башта авыррак барды. Мәсәлән, татарча хәреф кулланмый, татарча текстлар да бик аз иде. Хәзер инде татарча яза, русча текстларны татарчага тәрҗемә итеп куя, ул үзгәрде. Президент – кызыклы тренд булдыручы да. Аның хәерле иртә теләвен беркем дә кабатлый алмый, кабатласа да, алай килеп чыкмый. Иң зур челендж дип тә әйтергә була аны.

Минем аңа язылганга киләсе елда ун ел була. Элегрәк, ул да миңа язылсын, лайклар куйсын иде, дип хыялландым. Ул яктан Рөстәм Нургали улы – чын татар блогеры, блогерларның кызыклы постларына лайк та куя, комментарийлар да яза.



«МӘДӘНИЯТ ГАДИ ГЕНӘ ТӨШЕНЧӘ ТҮГЕЛ. ПРЕЗИДЕНТ МОНЫ ЯХШЫ АҢЛЫЙ»

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты, халык артисты:

Гомумән алганда, мәдәниятка, сәнгатькә хөкүмәтебез тарафыннан даими ярдәм күрсәтелә. Мәсәлән, яңа биналар төзелә. Әйтик, Чаллы драма, «Әкият» курчак театрлары яңа биналы булды, «Мастеровые» театрларын биналы итү планда тора. Милли китапханә, Чаллы курчак театры өй түе үткәрде, Түбән Кама театры, Сабантуй, Чаллы сәнгать галереясы төзекләндерелде. Зур тарихи вакыйга – Камал театры да яңа биналы булачак. Болар – беренче чиратта, Рөстәм Нургали улының шәхсән мәдәниятка зур игътибар бирүе нәтиҗәсе. Ул мәдәниятнең гади генә төшенчә булмавын, уен-көлке, шигырь сөйләү белән генә чикләнмәвен, иң әүвәл халыкның милли гореф-гадәтләрен саклау икәнлеген төптән аңлый һәм игътибар үзәгендә тота. Кино тармагын гына алсак та, аңа саллы матди ярдәм күрсәтелә. Татарстан Дәүләт Советында кинематографиягә багышланган «түгәрәк өстәл» булды, анда Министрлар Кабинетының идарә рәисе хисап тотты һәм әлеге юнәлешкә тотылган саннарны атады. Кинематография дәүләт ярдәменнән читтә түгел. Башка проектларны алыйк. Шул ук «Үзгәреш җиле». Ул да бит эстраданы үсешкә этәргән саллы проектларның берсе.

Татарстан Президенты каршында Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе булдыру Минтимер Шәймиев тәкъдиме иде. Ул Рөстәм Миңнеханов ярдәме һәм хуплавы белән бүген матур нәтиҗәләрен дә бирә башлады. Язучылар берлегендә даими конкурслар уздырыла, алар милли мәдәниятебезне алга таба үстерү максаты белән эшләнә. Конкурс дибез икән, «Милли мультифест»ны искә алыйк. Гомумән, яшьләрне мәдәниятка тарту, ана теленә мәхәббәтне уяту җәһәтеннән республикада зур эшләр башкарыла. Әлбәттә, республика җитәкчесендә хуплау һәм яклау тапмаса, алар тормышка ашмаган булыр иде.

Мәдәният кешенең дөньяга карашын формалаштыра. Республика җитәкчесе аны яхшы аңлый һәм Татарстанда яшәгән һәрбер халыкка фольклор ягыннан булсынмы, телләрне өйрәнү булсынмы – барлык мөмкинлекләр булдырыла. Халыклар Дуслыгы ассамблеясының эш нәтиҗәләре, якшәмбе мәктәпләренең эшчәнлеге – болар барысы да мәдәният дигән феноменны тудыра. Шуңа күрә безгә игътибар җитми дип зарлану дөрес булмас иде. Кешегә һәрвакыт нидер җитми, нәфес дигән нәрсә дә бар. Әмма Татарстан Республикасы мәдәниятка игътибар һәм матди ярдәм күрсәтү ягыннан беренче рәтләрдә бара. Бу җәһәттән Рөстәм Нургали улына исәнлек-саулык, хәерле озын гомер, җан тынычлыгы телим. Сәнгатькә булган игътибар кимемәсен иде. Иҗат әһелләренә исә күрсәтелгән ярдәмне акларга кала. Бу – үзебезнең милли кадрларны булдыру дигән сүз дә. Без үз йөзебезне югалтмаска, үткән һәм киләчәк буын арасындагы чылбырны өзмәскә тиешбез. Театрларны алсак, дәүләт акчасына кән күрә икән, аларга милли сәясәтне югары кимәлдә, сыйфатлы алып бару бурычы йөкләнгән. Бу – гомумән, барыбызның да зур бурычы. Мондый җитәкчелек булганда, чынга ашмаслык эш түгел. Куелган үрләрдән аска төшмәскә, яңа сәнгать әсәрләре белән тагын да биегрәк үрләр яуларга кирәк. Чөнки сәнгать ул – мәдәниятнең югары ноктасы, дәрәҗәсе.

«УЛ ДА ЯШЬЛӘРДӘН ЭНЕРГИЯ АЛА»

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА,
«Сәләт» яшьләр үзәге директоры:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның яшьләр тармагы, яшьләр сәясәтенә, аерым алганда, «Сәләт» хәрәкәтенә булган игътибары, ярдәме зур һәм чиксез. Беренче чиратта, ул безнең эшчәнлекнең балаларыбыз, яшьләребез һәм гомумән республикабыз өчен ни дәрәҗәдә кирәкле булуын үзе ук ассызыклый. Безгә карата һәрдаим югары бурычлар куеп тора. Без исә аның өметләрен акларга тырышабыз. Иң кызыгы шул: Президентыбыз куйган бурычларны беренче адым алга карап куышлган булуына без эшли-эшли инанабыз. Рөстәм Миңнеханов һәрвакыт безнең балаларга һәм яшьләргә бәйле булган проектларга булыша. Инфраструктура, әнтәлек ягыннан, дисенме, киләчәгебез саналган балаларыбыз өчен иң яхшысы булсын дип кайгырта. Соңгы елларда барлыкка килгән инфраструктура корылмалары да моңа дәлил. Алар барысы да бүгенге көн шартларына туры килә торганнардан.

Безнең Президентыбыз ярдәме белән Биләрдә оештырыла торган форум да үсте. Ике смена эшли торган форумыбыз хәзер инде 6 сменада балалар кабул итә. Җәй саен уку-укыту форумында дистәләгән мең бала катнаша. «Сәләт» клубларының елдан-ел ишәюендә дә Президентыбыз өлеше зур.

Мәгълүм булганча, Татарстан буенча «Адымнар» күптелле мәктәпләре эшли. Анда безнең «Сәләт» класслары эшли. Бу да безнең Президентыбызның бурычы иде, без моңа алындык.

Бу әле – ул күрсәткән зур ярдәмнең бер өлеше генә. Без аңа һәм аның командасына рәхмәтле.

Бу – «Сәләт» җитәкчеләренең генә фикере түгел. Ул балаларныкы белән дә тиңдәш. Без алан, җыен, форумнар кысасында еш кына сораштырулар оештырабыз. «Кемнәрне күрәсегез килә?» – дип сорыйбыз. Уңышка ирешкән шәхес дигәндә, Рөстәм Нургалиевич исеме еш яңгырый.

Күптән түгел Халыкара мәктәптә булдым. Презентациядә бер слайдта Рөстәм Миңнехановның сурәте куелган иде. Аны күрүгә балалар дәррәү кул чаба башлады. Бу инде әлеге шәхеснең балалар арасында абруйлы булуын, ышанычлы лавнның бер дәлиледер. Мин моңа сөендем.

Рөстәм Миңнеханов чаралар кысасында балалар белән шәхсән очраша, аралаша, тәләкләрен җиткерә. Бу очрашулар, һичшиксез, балаларда гомерлек истәлек булып калачак. Балаларда Президентыбызга карата хөрмәт көчле. Һәм аңа да алардан уңай энергия кире кайта дип саныйм.

Форсаттан файдаланып, Рөстәм Миңнехановка нык ныклы сәламәтлек, энергия, бәхет телибез.

«ИШЕГАЛДЫНА ЧЫККАН САЕН АҢА РӘХМӘТ УКЫЙБЫЗ»

Мөнирә ХӘЙРУЛЛИНА, пенсионер:

Казанның Глушко урамында яшим. Ишегалдыбызга күп еллар ремонт ясалмаган иде. «Безнең ишегалды» программасы кабул ителгәч, балта ышанмадык та. Әкренләп, төзекләндерү эшләре башлангач, күңелгә җылы керде. Хәзер урамнан керәсе дә килми. Тизрәк җәй не котәбез. Эскәмияләребез таушалган иде. Аларны яңартып куйдылар. Ишегалдына юллар салдылар. Тротуарларны машиналар менә алмаслык итеп эшләделәр. Бик тә рәхәт хәзер. Балалы әниләр дә коляска белән йөри ала. Машина куяр өчен махсус урыннар барлыкка килде. Балалар мәйданчыгында исә яңа җиһазлар куелды.

Безнең йортта яшәүче барлык кешеләр исеменнән Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка рәхмәтләребезне җиткерәм. Әйткән сүзен үтәүче, башкаларны үз артыннан ияртеп эшләтә белүче кеше ул. Исәнлек-саулык телим. Беләсезме, урамга чыккан саен без аңа рәхмәт укыйбыз, озын гомер телибез.

Балалар күзлегеннән

ӘТИ КЕБЕК ПРЕЗИДЕНТ АБЫЙ

Зилә ХӘБИБУЛЛИНА,
Татарстанның «Балалар оешмалары берлеге» җитәкчесе:

Президент – ул кәттә абый! Һәр иртә аның «Инстаграм»дагы сәхифәсенә керәм дә, Казаныбыздагы Ирек мәйданының ничек үзгәргәнен карап, барлык республикабыз халкына Рөстәм абый белән бергә хәерле иртә телим. Президент олы дустыбыз кебек! Татарстаныбызда яшәүче кешеләрнең тормышлары өчен җан атып, һаман да камиллеккә омтылып, нур сибеп яши! Президент абый – сокландыргыч шәхес! Минем дә, үскәч, Рөстәм абый кебек көчле, зирәк, киң күңелле һәм акыллы буласым килә. Үз алдыма куйган бурычларны төгәл үтәп, тормышыбызны ямьләндерергә телим.

Сабир СӘФӘРОВ,
Казан шәһәрендәге 2 нче татар гимназиясенең 4 нче сыйныф укучысы:

Минем өчен Президент – мөһим кеше. Чөнки ул дәүләт эшен башкара. Ул дәүләт эшен башкармаса, дәүләт булмый. Ә дәүләтсез бер кеше дә яши алмый.

Алия САБИРҖАНОВА,
«Шаян ТВ» телеканалы алып баручысы:

Минем өчен Президент ул – үрнәк, ышанычлы кеше. Рөстәм Нургалиевич – туган җиребезнең тынычлыгы, милләтебезнең якты киләчәге символы. Үткәнне истә калдырып, бүгенгенең кадерен белеп, киләчәкнең якты, матур, тыныч булачагына ышандырып, шуңа шартлар тудырып торучы кеше.

Камилә ЮНЫСОВА,
«XXI гасыр лидеры» бәйгесе җиңүчесе:

Минем өчен Президент ул – республиканың йөзе. Рөстәм Нургали улы – чын мәгънәсендә, бик зирәк һәм укымышлы кеше. Алай булмаганда, үз җилкәсендә шундың кадәрле зур җаваплылыкны күтәрә алыр идеме икән? Татарстаныбызның киләчәге нинди вакыйгалар белән үрелгән ул хәл итә. Тормышыбызның тулылыгы да аның кулларында. Һәм, әлбәттә, Рөстәм Миңнеханов яшьләр белән бер дулкында булуы белән аерылып тора. Ул һәрвакыт безгә ярдәм итәр өчен кулыннан килгәнне эшли. Мин бик бәхетле. Чөнки узган ел Рөстәм Нургали улы белән очрашып, аңа үз проектым турында сөйли алдым.

Фәридә ГАТИНА,
«Сабантуй» журналының яшь хәбәрчесе:

Минем өчен Президент ул – үз халкының башлыгы. Ул нәкъ әти шикелле: безне кайгырта, безгә әйбәт булсын өчен көн күңелдән тырыша. Президентны бөтен кеше дә тыңлый, ул – бик хөрмәтле кеше.

Алия ГЫЙМАЗОВА,
Мамадыш районының Кече Кирмән авылы мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы:

Минем өчен Президент ул – яхшы күңелле, олы – олы, кечене кече итә белә торган, тырыш һәм максатчан шәхес. Безнең республика территориясен генә карагыз: нинди зур бит ул! Шул җирләкнең, анда яшәүче кешеләрнең киләчәген кайгырту җиңелләрдән түгелдер. Ләкин Рөстәм Нургали улы бу эшне яхшы башкара дип уйлыйм мин. Әбием да шулай ди. Ул гел телевизор карый, Президентыбызның чыгышларын аеруча игътибар белән тыңлый. «Яхшы тормышта яшибез», – дип еш кабатлый. Ә әбигә ничек ышанмыйсың һәм аның белән ничек килешмисең ди?!

«ЯШЬТӘН ҮК ҖИТӘКЧЕ СЫЙФАТЛАРЫ СИЗЕЛӘ ИДЕ»

Мәгъдәнур ГАТАУЛЛИН,
Рөстәм Миңнехановның остазы:

Без Рөстәм Миңнеханов белән Саба «Сельхозтехника»сында таныштык. Ул институтны тәмамлагач, эшкә кайтты. Кечкенә генә буйлы егет иде. Рөстәм техник хезмәт күрсәтү станциясенә инженер булып урнашты. Вергә ике ел эшләдек. Ул чакта ук җитәкче сыйфатлары бар иде. Бу, мөгаен, бераер зур кеше булыр, дип уйлый идек. Мин токарь булгач, Рөстәмнең гел йомышы төшә иде. Кереп эш тә кушып чыгып китә. Яшь булса да, бик тиз абруй яулады. Кешеләргә хөрмәт белән карый иде. Мин аның тавыш күтәреп сөйләшкәнен хәтерләмим. Кызу чагын да хәтерләмим. Әмма шунысын беләм: Рөстәм кузенә карап, турысын әйтә. Бөтен республика яратып безнең. Бу – барысы да Президентның хезмәте. Туган көне белән котлап, саулык-сәламәтлек телим. Халкыбыз өчен күп эшли, ял итә аламы икән, дип тә борчылам. Иртәгә үземә дә 81 яшь тула. Рөстәм мине белә ул. Әле бер елны очрашып сөйләшеп тә тордык. «Инстаграм»ына да куйган иде.

«ПРЕЗИДЕНТ НИНДИ, ХАЛЫК ШУНДЫЙ»

Салават ФӘТХЕТДИНОВ,
Татарстанның халык артисты:

Халыкта, нинди җитәкче – шундый коллектив, дигән сүз йөри. Димәк, Президент нинди – халык шундый. Энергияле, тырыш Президентның халкы да нәкъ үзе кебек. Рөстәм Миңнеханов бик зур эш башкара, Татарстан халкының тормышы өчен җаваплы ул. Без – татарлар – уңган халык. Бездән башкалар көнләшсәләр дә, аны мактау итеп кабул итәргә кирәк. Булган кешедән генә көнләшәләр, шунысын да онытмыйк. Республикабыз тагын да ныграк чәчәк атсын, балкысын өчен бергәләшеп хезмәт итик.

«АТАЛАРЧА КЫЗЫКСЫНА БЕЛДЕ»

Фәрһад ФӘТКУЛЛИН,
синхрон тәрҗемәче, 2018 елгы «Ел викимедиачысы», татар телле Википедия активисты:

Татарстан һәм гомумән татар халкы өчен Рөстәм Миңнеханов эшчәнлеген бары тик уңай бәяли алам. Премьер-министр чагында да, аннан Президент вазыйфасына сайлангач та, ул җитәкләгән команда белән күп кенә чараларда тәрҗемәче буларак эшләргә туры килде.

Бу җәһәттән, бер вакыйга искә төште әле. Швейцариядә уза торган Давос форумында булды ул. Татарстан партнерлары белән очрашу-аралашу вакытында Рөстәм Нургалиевич кыска бер вакыт аралыгында шәхси уйларына чумды булса кирәк. Миңа борылды да әти-әниемнең саулыкларын сорашты. Гаиләм белән кызыксынды. Балаларым белән һәр атна кунакка йөрүләребезне әйтүемә, йөзендә шатлык билгеләре күренде. Жылы сүзләр әйтеп, үз эшен дәвам итте. Аталарча кызыксынды.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күренекле журналист, танылган язучы, күпсанлы җырлар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Бәллүр каләм» иясе лауреаты, Казандагы «Спас» якташлык җәмгыяте президенты Камил Шәмгун улы СӘГЪДӘТШИНның 70 яшьлек олуг юбилее.

Кадерле дустыбыз Камил Шәмгунович!

Сине ихлас күңелдән юбилееӊ белән тәбрик итәбез. Син үзенчәлекле датада – 29 февральдә тугансың. Меңнәр бәхете өчен күктән иңдерелгән фәрмандыр бу.

Син һәрдаим күңелебездә тугры дус, олы җанлы, зыялы шәхес булып яшисең. 5 ел буе группабызның профком рәисе булдың. Һәркайсыбызга авыр чакта ярдәм кулын сузып килдең. Хәзер дә шундый ук затлы, кешелекле син! Безнең горурлыгыбыз! Әниеңне зурлап, тәрбия кылып, исән чакта тәхеткә утырттың. Чын ир-егет солтаны да син! Гомерлек ярың – Фәйрүзәң белән ил-көн каршында лаеклы, сәләтле балалар – Илдар белән Диләрәне үстердегез. Туганлыкның асыл сыйфатлары да синдә тупланган. Һәркайсы белән аралашып, ярдәм итешеп яшисез. Бусы да күпләр өчен өлге булырлык. Синең мәрхәмәт тулы йөрәгеңдә һәркайсыбыз өчен урын бар. Гаҗәеп киң күңелле син! Туган ягың халкына да биниһая зур ярдәм күрсәтеп яшисең.

Киләчәк елларда сиңа нык сәламәтлек, иҗади уңышлар, матур хатирәләреңне барлап яшәргә язсын!

Олы ихтирам белән, синең яшьлек һәм гомерлек дусларың – 495 группа студентлары – Владислав Фронин, Марсель Галиев, Алсу Бикбаева, Александр Дороган, Нурия Сәйяр, Әминә Миңнуллина, Татьяна Устиновская, Гөлфәния Хөсниева, Ренат Гаффар һ.б.

Мамадыш районының Түбән Яке авылында гомер итүче Мөсавәрә Шәкрам кызы ДӘҮЛӘТШИНАның 1 мартта туган көне. Әниебезгә 85 яшь тула.

Кадерлебез! Сине чын күңелебездән олы бәйрәмең белән тәбрик итәбез. Күрше Югары Яке авылында туып үсеп, әтиебез Ильяска кияүгә чыга ул. Алар бөтенебезгә үрнәк булып 62 ел тигез гомер иттеләр. Әтиебез авылыбыз мулласы булып торды. Без – аларның алты баласы муллыкта, татулыкта, әти-әни яратуында үстек. Авыл мәктәбендә укыганда да алдынгылар рәтендә идек. Соңыннан барыбыз да төрле шәһәрләргә китеп, югары белем алдык. Әле дә шулай таралышкан килеш, үз тормышыбыз белән яшибез. Әниебез узган ел ялгыз калды. Әтиебез үз туган көнендә, 89 яшен тутырып, бакыйлыкка күчте. Буй җитсәк тә, әни җылысын тоеп яшәгәнебезгә сөенеп туя алмыйбыз. Озак яшә, авырма, син безгә бик кирәк, әни!

Сине яратып, 16 онык, 5 оныкчык, балаларың, кияү-киленнәрең исеменнән кызың Нурсинә

Спорт

БУЛАЧАК БАТЫРЛАР БИЛ АЛЫШТЫ

Казанның «Тулпар» спорт комплексында 17–18 яшьлек егетләр арасында «Татарстан яшьләре» газетасы призларына милли көрәш бәйгесе узды. Үз авырлыкларында җиңүче булып Илфат Миңнегалиев (Азнакай), Рубин Раджабов (Әлмәт), Данис Садриев (Яңа Савин, Казан), Даил Зиннәтуллин (Әтнә), Илназ Шәмсиев (Актаныш), Динияр Моратов (Арча), Инсаф Хәйруллин (Кукмара), Азат Хәмдиев (Яңа Савин, Казан), Румил Семкичев (Әлмәт) танылды. Командалар ярышын Казанның Яңа Савин районы егетләре отты. Кукмара көрәшчеләре – икенче, Арча егетләре өченче булды.

БИШЕНЧЕ ҖИҢҮ

Татарстан җыелма командасы чаңгы узышлары буенча Россия Кубогына ия булды. Бу – якташларыбызның 5 нче җиңүе. Татарстан чаңгычылары мондый уңышка рәттән 4 нче тапкыр ирешә. Безнекеләр ир-егетләр беренчелегендә дә, хатын-кызлар арасында да беренче булды. Гомуми зачетта республика спортчылары икенче урындагы Төмән командасын 3523 очкога артта калдырды.

Россия Кубогының 27 февральдә Төмәндә узган ахыргы ярышында спортчылар скиатлонда көч сынашты. Ир-егетләр арасында 30 чакрымлык дистанциядә Татарстаннан Антон Тимашов җиңү яулады. Хатын-кызлар арасында 15 чакрымлык узышта якташыбыз Алия Икъсанова өченче булды.

КУДЕРМЕТОВА КҮТӘРЕЛӘ

Россия спортчысы Даниил Медведев ир-егет теннисчылар рейтингында беренче урынга күтәрелде. Моңа кадәр Россиядән мондый уңышка 1999 елда Евгений Кафельников һәм 2001дә Марат Сафин гына ирешә алган иде.

Казан кызы Вероника Кудерметова исә хатын-кыз теннисчылар рейтингында 25 нче урынга күтәрелде. Россия спортчылары арасында иң яхшы күрсәткеч Анастасия Павлюченкованыкы – ул 14 нче урында.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

ТЕЛ САКЧЫСЫ ИДЕ...

Югалту

Татар журналистикасы зур югалту кичерә. 86 яшендә филология фәннәре докторы, профессор Илдар Низамов арабыздан китеп барды. Телнең сафлыгы өчен аннан да ныграк борчылган кеше булдымы икән ул?

Ләйлә Сабирова

Илдар абый шәкерте булу бәхете миңа да эләкте. Ул бик таләпчән, шул ук вакытта гадилеге, һәр баланы якын итүе, гадел булуы белән күңелебез түренә үтеп керде. КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире, профессор Васил Гарифуллин да – Илдар Низамов шәкерте.

– Безне сиксәненче еллар башында Казан дәүләт университеты очраштырды. Ул чакта ук әдәби мәйданда зур танылу алган бу шәхес безгә практик стилистика буенча дәресләр бирде. «Газета теле» дигән зур бер сөйләм катламының закончалыкларына төшендерде, аның матур якларын күрсәтеп бирә белде. Тел чаралары ярдәмендә зур аудиториягә тәэсир итүнең нечкәлекләрен ачты. Ул телнең матурлыгын күрергә, газета битләреннән «энҗе», «җәүһәр» җыярга өйрәтте, – ди Васил Гарифуллин. – Илдар абый телнең асылын, байлыгын яхшы белгән журналистлар тәрбияләде. 2012 елда ялга китсә дә, ул гел шалтыратып, эш сорап кына торды. «Нинди эшең бар?» – дияр иде. Бер дә тик торырга яратмады. Әдәби әсәрләре, документаль хикәяләре күп иде. Туган ягы турында парчалар да язды. Кафедра өчен зур хезмәтләр калдырып китте. Аның 85 яшьлек юбилеена «Авазга мәдхия» дигән китабын чыгарган идек. Студентлар өчен зур ярдәмлек ул. Анда радио, телевидение сөйләме хакында язылган.

Васил Гарифуллин Илдар абый белән гел элемтәдә торган. Ул аның хакында бик озак сөйли ала. Әле менә соңгы елларда туган ягына тартылуын да искә алды. Илдар абый авылдагы бакчасында бәрәңгесен дә үстергән, җиләк-җимеш бакчасын да тәртипләп торган. Гөмбә җыярга яраткан, балык тотарга йөргән. Алар хатыны Мөсфия апа белән гел бергә булганнар.

– Илдар кебек кеше бүтән юк ул. Без аның белән 62 ел бергә яшәдек. Бик акыллы кеше иде, гадел, таләпчән булды. Туганнары да бик якын итеп тордылар. Тормышта төрле чаклар булгандыр. Әмма мин бер дә зарлана алмыйм. Илдар абыегыз мине бик бәхетле яшәтте, – ди Мөсфия апа.

Журналист Данил Сәфәров та остазы турындагы истәлекләре белән бүлеште:

– Без 1997 елда укырга кергәндә, Илдар абый олы кеше иде инде. Ул чакта аңа 61 яшь булган икән. Өч курс алдан укыган Алмаз Миңнуллин, Илдар Сәгъдәтшин безне куркытып та куйдылар: «Берәрегез Казанныкымы? Илдар абыйдан зачет бирә алмаячаксыз. Шәһәрнекеләрне яратмый ул». Ни өчен «яратмаганы» соңыннан аңлашылды. Калада туган баланың теле ни татар, ни урыс түгел. Илдар абыйның дәресләрендә йоклап утырып булмый иде. Бер-ике җөмлә әйтә дә сорау бирә. Ә мин аның белән еш бәхәсләшә идем. Ул бәхәсләшкәнне ярата. Русча фикерлисез, калька кулланасыз, дип шелтәли иде.

Данилнең үкенече дә бар. Илдар абый авылга кунакка чакырган булган аны. Балыкка барыр идек, дип тә караган. Данил кайта алмаган. Әмма алар гел телефоннан сөйләшеп торганнар.

– Өйдә бер көеме, балаларың ничек, дип сорый иде. Илдар абый «Матбугат.ру» сайтында «Ана теле» сәхифәсен алып барды. Попса һәм хайп заманында аның язмалары чагыштырмача әзрәк карау җыя иде. Әмма ул фәлән кеше укыган бит дип шатлана белде. Сезнең язманы укыган мең кеше җырчылар турында укыган ун мең кешедән кыйммәтрәк, дия торган идем, – ди Данил.

Төркиядә яшәүче милләттәшебез, язучы Айзирәк Гәрәева-Акчураның да Илдар абыйга бәйле истәлекләре бихисап:

– Курс эшләрен 3 нче курста иң таләпчән укытучы буларак даны чыккан Илдар абый җитәкчелегендә куркып кына яза башлаганым хәтердә… Берара ул әйткән темалар буенча мәкаләләр язып йөргәнем, кат-кат төзәтүе, кат-кат яздырганы, шуннан соң үзе үк аларны «Мәдәни җомга»га илтеп биргәне истә. Аннары, көннәрдән бер көнне 13 нче кат коридорында очрап яки дәрес алдыннан «Күрдеңме?!» дип, кош тоткандай сөенеп сорар. Газета басылып чыккан мәкаләң өчен синнән дә болайрак куаныр! Без укыган чорда газета-журналларны университет китапханәсенә кереп караш яки киоскка чабып барып алыш иде.

Университетны тәмамлагач, Айзирәк «Шәһри Казан»га урнаша. Шушы вакытта алар тагын Илдар абый белән очраша.

– Ул – университетта студентларның иҗади эшләре җитәкчесе, ә мин үземчә, редакциядә алар белән эшлим. Семестр ахырын бераз борчылып та, дулкынланып та көтеп алам. Һәм менә Илдар абый студентларның рефератлары, курс эшләре белән тулган күн сумкасын күтәреп йөгереп килеп җитә! Редакциядә студентларның иҗади эшләренә бергәләп нәтиҗәләр чыгарабыз, язмаларын тикшерәбез, фикерләшәбез, – дип искә ала Айзирәк. – Студентлардан бигрәк, мин сабак алып утырам! Чөнки студент чакта бер төрлерәк уйлыйсың, эшли башлагач, гыйлем кыйммәте тагын да үсә, тагын да аңлабрак карыйсың бит. 2–3 сәгать вакыт очып кына уза. Ул арада Илдар абый сәгатенә ешрак күз сала башлый, башка дәресенә ашыгып чыгып китә. Әле генә язма телебезне шомарткан, төзәткән мисаллары, киңәшләре белән бергә «балакайлар» дигән сүзе студентлар күңеленә, минем күңелгә кереп кала иде.

Илдар Низамовны 24 февральдә Казан хастаханәсенә салалар. Нишлисең, савыгып, үз аягы белән өенә кайтырга насыйп булмаган шул… Кичә аны туган ягына – Әтнә районының Чишмәле Сап авылына җирләделәр. Җәннәтле бул, Илдар абый!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ГОМЕР БӘЯСЕ – 300 СУМ?

Яңалык

Агымдагы елның 1 мартыннан яңа төзелә торган торак йортларның барысына да янгын хакында хәбәр итүче җайланма куячаклар. Бу хакта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Күзәтчелек һәм профилактика эшчәнлеге департаменты директоры Ринат Еникеев хәбәр итте.

tatarstan.ru

Сан

Янгын чыгуны кисәтүче җиһаз Татарстанда **2016** елда куела башлый. Республикада соңгы **5** ел эчендә ул **86** янгын хакында хәбәр бирә. Шул рәвешле **174** кешене коткаралар. Быел кисәтүче җайланма **2** кешенең гомерен саклап кала.

– Кагыйдәләр җыелмасына яңа төзелгән йортларда янгын сигнализациясе һәм махсус датчиклар урнаштыруга бәйле таләпләр кертелде. Янгын турында хәбәр итү җайланмалары янгын сигнализациясе системасы булмаган күпкатлы йортлардагы барлык фатирларда да мәҗбүри рәвештә куелачак, – диган иде ул бер очрашуда.

Уч төбенә сыярлык җайланма кеше гомерен коткарып кала. Ул, өйдә төтен чыгуга, хәбәр бирә. Хәтта аш бүлмәсендә берәр ризык көеп китсә дә, ачы тавыш белән кычкыра башлый. Батареялар ярдәмендә эшләүче җайланманы түшәмгә беркетәләр. Бәясе дә кыйммәт түгел, 300–400 сумга алырга була. Гадәттә, йортларга ул җиһазны берничәне куялар. Җиһазның куәтлерәге дә бар, анысының бәясе – 2500–4000 сумга кадәр. Чаллыда яшәүче Айдар Насыйбуллин үз фатирына да, авылда яшәүче әнисенә дә әлеге җайланманы куйдырган.

– Узган ел декабрь аенда әниебезне шушы җайланма коткарды. Әти вафатыннан соң, күпме генә чакырсак та, безнең белән яшәргә шәһәргә күченмәде. Ноябрь аенда, күңелем сизенепме, шушы җайланманы алып кайтып куярга булдым. Әнием газга таба куйган да урамга чыгып киткән. Ут өстәлдәге чүпрәккә капкан. Ярый әле әни әлеге җайланманың тавышын ишетеп, өйгә кергән. Юкса өебез янып бетәр иде. Янгын чыгуны кисәткеч йортыбызны да, әниебезне дә саклап калды, – ди Айдар.

Билгеле булганча, социаль яктан имин булмаган, матди яктан кыен хәлдә калган гаиләләргә, физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә, шул исәптән авыру бала тәрбияләүчеләргә, күпбалалы гаиләләргә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, 70 яшьтән узган өлкәннәргә әлеге җиһаз бушлай куела.

– Әлеге җиһазларны баштарак халык аңлап бетермәде. Өлкән кешеләр, батареясы бетеп, тавыш биреп утырганына да борчыла иделәр. Хәзер бик теләп куйдыралар. Татарстан Президенты ярдәме белән җиһазлар бушлай кайтарыла. Районның социаль яклау бүлеге аша җайланмаларга гариза биреп була. Әгәр кешегә бушлай тиеш түгел икән, ул очракта сатып алалар инде. Хәер, соңгы елларда халык үзе дә уяуланды, йортларын мөстәкыйль җиһазландыручылар да бар, – ди Балтач районының Сосна авылы җирлеге башлыгы Фәнил Габдрахманов.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7101 данә

Гомуми тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 229

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.

N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.

Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+